ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2019 Олы Кайбыч авылы № 201

Кайбыч муниципаль районында 2018-2019 еллар ягу сезоны тәмамлану һәм 2019-2020 еллар көзге-кышкы ягу чорына әзерләнү турында

Уртача тәүлеклек уңай тышкы һава температурасы урнашу сәбәпле, РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы «Милекче һәм кулланучыларга күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» карары нигезендә һәм торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрен, ягулык-энергетик комплекс һәм социаль мәдәни көнкүреш объектларын 2019-2020 еллар көзге-кышкы ягу чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатында, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Кайбыч муниципаль районы социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүче предприятие һәм оешмаларга тәкъдим итәргә:

1.1. 2018-2019 еллар ягу сезонын 2019елның 29 апреленнән тәмамларга.

1.2. Пар казаннары бинасында, үзәк җылылык пунктларында, җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрендә һәм эчке инженер системаларында объектларны көзге-кышкы ягу чорына әзерләү чаралары нигезендә ремонтлау һәм профилактика эшләрен башларга.

2. Объектларны 2019 - 2020 елларның көзге-кышкы чорына әзерләүне 2019елның 15 сентябренә тәгәлләргә.

3. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров